# Мәҗлес кенә түгел:
## Алабугада тематик ифтарлар уза

Рухият

Альбина **КЕЛЬШ**

**(Башы 1нче биттә)**

Ул билгеләп үткәнчә, яшьләр өчен оештырылган ифтарда шәһәрдәге мөселман кибетеннән килгән Гүзәлия ханым хатын-кызларны матур итеп яулык ябарга өйрәтә, мөселман динендәге хатын-кызларның ничек матур киенә алуын күрсәтә. Инде традицион рәвештә, ул катнашучыларга бүләкләр дә бирә, намазга басарга теләк белдерүчеләргә намазлык, күлмәк, дисбе тапшырыла.

Икенче ифтарга медицина хезмәткәрләрен чакырганнар, чарада шәһәрнең төрле медицина учреждениеләре – Алабуга үзәк район хастаханәсе, теш дәвалау поликлиникасы, шәһәр сырхауханәсе, хатын-кызлар консультациясе хезмәткәрләре, балалар бакчаларыннан шәфкать туташлары катнашкан.

Өченче ифтар укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен үткәрелгән.

Лилия ханым билгеләп үткәнчә, гадәттә мондый ифтарларда 70 кә якын кеше катнаша.

Һәр тематик ифтарда кичәдә катнашучыларга якын булган темага хәдисләр укыла. Яшьләргә – яшьләр турында хәдисләр һәм аятьләр, медикларга – Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәребезнең шифа турында сүзләре, укытучыларга белем бирүгә бәйле хәдисләр, файдалы киңәшләр тәкъдим ителә.

Шулай итеп, әлеге кичәләрнең тәрбияви-әхлакый әһәмияте дә бәяләп бетергесез. Анда килүчеләр мәҗлестә катнашып кына калмый, үзләре өчен рухи азык та алып китә.

– Мондый ифтарлардан соң, мәчеттә үтә торган намаз дәресләренә янә өч кеше килде. Бу безнең өчен бик сөенечле, – дип уртаклаша Лилия ханым.

– Ислам диненең җиңеллеген, монда бернинди авырлык юклыгын, гыйбадәт кылуның да бик рәхәт булуын күрсәтә алсак, без бик шат. Ислам – ул яшәү рәвеше. Без уйный да беләбез, шаяра да беләбез, төрле экскурсияләргә йөрибез. Әле Яңа елдан соң Казанга Галиәсгар Камал театрына бардык, гаилә елы уңаеннан бик матур спектакль карап кайттык, ханымнарга бик ошады, – дип сөйли ул.


Һәр тематик ифтарда 70 ләп кеше катнаша./ФОТО: ЛИЛИЯ ФАЗЛЫЕВА.

Авыз ачу мәҗлесләрен оештыруда яшьләр дә актив катнаша. “Әҗмәл” мәчетендә “Исламда хатын-кыз” дип исемләнгән тематик ифтарны яшь мөслимәләр оештырган. Үзләре әйтүенчә, башкалабыз Казанда уза торган фэшн-ифтар белән рухланганнар, һәм бездә дә шундый чара үткәрү идеясе барлыкка килгән.

– Әлеге ифтарда актуаль темалар күтәрелә, шул ук вакытта кызыклы программа төзелә, мәсәлән, модалы киемнәр күрсәтү уза. Үзебезгә дә шундый чара үткәрергә кирәк, дип хәл иттек һәм тәвәккәлләдек. Мондый авыз ачу мәҗлесе беренче мәртәбә узган елны үткәрелде, ул вакытта чара “Йолдызлык” мәдәни үсеш үзәгендә узды, – дип сөйли оештыручыларның берсе Альбина Сабирова.

Тематик ифтарга дингә күптән түгел генә килүчеләрне чакырырга, күбрәк яшьләрне җәлеп итәргә булганнар.

– Әлбәттә, хатын-кызларның исламда роле турында сөйлисе килде, чөнки җәмгыятебездә әле дә стереотиплар яши. Әгәр хатын-кыз диндә булып, яулык кия икән, ул бөтенләй җәмгыятьтән аерыла, намазын гына укып утыра, дип уйлаучылар шактый. Ә бит киресенчә, ислам хатын-кызны олылый, аңа күп хокуклар бирә, төрле яклап яклый. Ифтарда шушы темага чыгыш ясадык, – ди Альбина ханым.

Кичәдә уеннар һәм викторина да үткәрелгән, анда катнашучылар сөйләнгән вәгазь буенча сорауларга җавап бирә. Логикага викторинада проекторда күрсәтелгән рәсем буенча җавапларны белергә кирәк була.

Ифтарда катнашкан 66 кеше арасында спонсорлар тәкъдим иткән 3 сертификат уйнатылган. Чара ахырында һәр катнашкан ханымга роза чәчәкләре бүләк итәләр.

– Дингә яңа килгән кешеләрнең мәчеткә керергә уңайсызланганнары да була, шуңа күрә без мөмкин булганча аларны исламга якынайтырга тырышабыз. Мондый чараларга кешеләр иркенләп килә, – ди Альбина Сабирова.

Катнашучыларның барысы да уңай хис-кичерешләре белән уртаклаша, мәҗлесләрдә тагын катнашырга теләк белдерә. Оештыручылар, үз чиратында, тематик ифтарларны ел саен үткәрергә ниятли. Альбина ханым әйтүенчә, быелдан ук әзерләнә башлаганнар, булган җитешсезлекләрне үзләре өчен билгеләп, киләсе елга эшне тагын да камилләштермәкчеләр.

# Китапханәдә Балалар китабы атналыгы узды

Балалар елы

**Ел саен, язгы каникул көннәрендә, традицион китапханә бәйрәменә әверелгән Балалар һәм яшүсмерләр китабы атналыгы билгеләп үтелә.**

Ул беренче тапкыр Мәскәүдә 1943нче елда күренекле балалар язучысы Лев Кассиль тәкъдиме белән үткәрелә. Шул көннән башлап, март ахырында Балалар китабы атналыгын уздыру матур гадәткә әйләнгән.

Гадәттәгечә, Балалар китабы атналыгын ачу бәйрәмендә яшь китап укучылар белән очрашуга язучылар, шагыйрьләр һәм театр коллективлары артистлары килә.

Быел Үзәк балалар китапханәсендә узган бәйрәмгә “Колос” мәдәният йортында эшләүче Милана Динисламова җитәкчелегендәге “Shiata” яшьләр театр студиясе артистлары һәм Әнвәр Бакиров исемендәге 1нче Балалар музыка мәктәбе мөгаллимнәре Марина Липатова, Әлфия Фәйрушина белән әлеге мәктәптә белем алучылар килде.

Китапханәчеләр бәйрәм уңаеннан төрле күргәзмәләр тәкъдим итте, анда татар телендәге матур китаплар, гадәти булмаган басмалар, балалар һәм яшүсмерләр өчен иң яхшы әсәрләр һәм башкалар белән танышырга мөмкин булды. Балаларга Россия дәүләт балалар китапханәсе архивыннан Балалар китабы бәйрәме тарихына багышланган фильм күрсәтелде. Чара кунаклары “Александр Пушкин әкиятләре” викторинасында да бик теләп катнашты. Шулай ук бу көнне “Пушкинның бөтен гаилә өчен әкиятләре” фотозонасы эшләде.

Быел Балалар китабы атналыгының девизы – “Гаилә укый – ил укый!” булды.

**Үзәк балалар китапханәсе**



1 апрельдән 2024 елның II яртыеллыгына район газеталарына язылу башлана
“Алабуга Нуры”на язылу бәясе – 910 сум, “Новая Кама” – 964 сум, әмма ...
Сезнең өчен шәп яңалыгыбыз бар!
Алабуга нуры 910 сум Новая Кама 964 сум
8 апрельдән 18 апрельгә кадәр “Алабуга нуры” һәм “Новая Кама”ны
өйгә китерерлек итеп язылуны ташлама белән рәсмиләштерергә була
Элеккечә үк, без язылуның альтернатив ысулын да тәкъдим итәбез. 6 айга язылу бәясе – нибары 500 сум!
Алабуга нуры 793 сум Новая Кама 839 сум
Бу очракта газеталарны түбәндәге адреслар буенча үзегез килеп алырга кирәк булачак:
- редакция (Төзүчеләр урамы, 16а),
- үзәк китапханә (Казан урамы, 15),
- шәһәр Мәдәният сарае (Нефтьчеләр проспекты, 24),
- “Йолдызлык” мәдәни үсеш үзәге (Тынычлык проспекты, 77).


Район газеталарына язылырга һәм вакыйгалардан хәбәрдар булырга ашыгыгыз.
“Алабуга нуры” һәм “Новая Кама” – гаилә укуы өчен газеталар!
реклама